| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 07.08.2019 | Алабуга шәһәре | № 392 |

**2011 елның 21 июнендәге 111 номерлы «Алабуга муниципаль районында гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Алабуга муниципаль районы территориясендә яшәүче халыкның хокукый инициатива рәвешендә җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу хокукларын тәэмин итү максатларында, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26 маддәсенә, Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. 2011 елның 21 июнендәге 111 номерлы «Алабуга муниципаль районында гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Алабуга муниципаль районында гражданнарның хокукый инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмәнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Сайлау комиссиясе, аны булдыру тәртибен бозган очракта, шулай ук тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәнең 3.3, 4.1 пунктлары таләпләренә туры килмәгән очракта, инициативалы төркемне теркәүдән баш тарта. Теркәлүдән баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Г.Е. Емельянов